**Татарстан Республикасы**
**Чирмешән муниципаль районының**
**«Мордва Афонькәсе авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге**
**гражданнар җыены**
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлеге составына керүче Лагерка торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**15 октябрь 2025 ел** **№ 1/5**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2025 елның 15 октябрендә киләсе мәсьәлә буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2026 елда Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлегенең Лагерка торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасында һәм Донецк халык республикасында махсус операциядә булган затлардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрү белән килешәсезме:

- **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту) торак пунктларда, трактор өчен ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, Лагерка торак пунктындагы балалар мәйданчыгын төзекләндерү, Лагерка авыл клубы янында территорияне төзекләндерү (эскәмияләр сатып алу);
- **электр элемтәләрен тәэмин итү һәм җиһазларның электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын ремонтлау** (урам яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру, торак пунктларда кулланыла торган электр энергиясе өчен түләү);
- **янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү** (янгын сүндерү өчен янгын җиһәзләре сатып алу).

- **коймаларны ремонтлау, кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү** (Лагерка авылындагы зиратта агач һәм куакларны кисү).

«РИЗА» «КАРШЫ».

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенының 185 катнашучысы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 95 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенының 95 катнашучысы тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен гражданнар җыенында 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә халык җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлегенең Лагерка торак пунктында халык җыены булып узган, халык җыены нәтиҗәләре - чын дип танырга.

2. Киләсе мәсьәлә буенча: «2026 елда Чирмешән муниципаль районы Мордва Афонькәсе авыл җирлегенең Лагерка торак пункты территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 сум күләмендә үзара салым кертергә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән, Луганск халык республикасында һәм Донецк халык республикасында махсус операциядә булган затлардан тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрергә:

- **торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү** (юл кырыйларын чабу, юлларны грейдерлау, кышкы вакытта урамнарны кардан чистарту) торак пунктларда, трактор өчен ягулык-майлау материаллары һәм запас частьләр сатып алу, тракторчыга исәпләнгән хезмәт хакы, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәт күрсәтүләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу, Лагерка торак пунктындагы балалар мәйданчыгын төзекләндерү, Лагерка авыл клубы янында территорияне төзекләндерү (эскәмияләр сатып алу);
- **электр элемтәләрен тәэмин итү һәм җиһазларның электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын ремонтлау** (урам яктырткычларын монтажлау, ремонтлау, алмаштыру, торак пунктларда кулланыла торган электр энергиясе өчен түләү);
- **янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү** (янгын сүндерү өчен янгын җиңсәләре сатып алу).
- **коймаларны ремонтлау, кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү** (Лагерка авылындагы зиратта агач һәм куакларны кисү).

3. Җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмати стендларда урнаштыру юлы белән игълан итәргә: Лагерка авылы, Школьная урамы, 22 нче йорт, Чирмешән

муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми интернет сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Мордва Афонькәсе авыл җирлеге башлыгы А.И.Митяев